**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2859**
**23.04.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.И. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 23 апрелендәге
2859 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУ
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифлар

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th>Хезмәтнең исеме</th><th>Үлчәү берәмлеге</th><th>Бәя сум</th></tr>
<tr><td>1.</td><td>Мунчаларда юыну хезмәтләре</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1.1</td><td>Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну хезмәтләре:</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә)</td><td rowspan="8">сәгать<br>(1 сәгать<br>45 минут)</td><td rowspan="4">бушлай</td></tr>
<tr><td></td><td>Бөек Ватан сугышы инвалидлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә)</td></tr>
<tr><td></td><td>диализда торучы, сәламәтлекләре буенча инвалидлар (документ күрсәткәндә)</td></tr>
<tr><td></td><td>7 яшькә кадәрге балалар (документ – туу турында таныклык күрсәткәндә)</td></tr>
<tr><td></td><td>1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә) яисә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар (документ күрсәткәндә)</td><td rowspan="2">100,00</td></tr>
<tr><td></td><td>һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары (документ күрсәткәндә)</td></tr>
<tr><td></td><td>барлык категория пенсионерлар<br>(барлык категория пенсионерларга гражданнарның башка категорияләре өчен каралган бәядән 60 сум күләмендә ташлама бирелә)</td><td>170,00</td></tr>
<tr><td></td><td>гражданнарның башка категорияләре</td><td>230,00</td></tr>
<tr><td>1.2</td><td>Мунча номерында юыну хезмәтләре:</td><td>сәгать<br>(60 минут)</td><td>681,77</td></tr>
<tr><td>1.3</td><td>Хаммамда (төрек мунчасында) юыну хезмәтләре:</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>7 яшькә кадәрге балалар</td><td>сәгать<br>(2 сәгать<br>45 минут)</td><td>бушлай</td></tr>
<tr><td></td><td>7 яшьтән 11 яшькә кадәрге балалар</td><td>сәгать<br>(2 сәгать<br>45 минут)</td><td>210,00</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гражданнарның башка категорияләре | сәгать (2 сәгать 45 минут) | 518,96 |
| | 7 яшькә кадәрге балаларга туу турында таныклык нигезендә гражданнарның башка категорияләре өчен каралган бәядән 100 % лы ташлама бирелә<br>7 яшьтән 11 яшькә кадәрге балаларга туу турында таныклык нигезендә гражданнарның башка категорияләре өчен каралган бәядән 60 % күләмендә ташлама бирелә | | |
| 2 | Бассейннан файдалану хезмәтләре: | | |
| | барлык категория гражданннар өчен | сәгать (45 минут) | 138,39 |
| | барлык категория пенсионерлар | | 105,00 |
| | Пенсионерларга пенсия таныклыгы нигезендә гражданнарның башка категорияләре өчен каралган бәядән 25 % күләмендә ташлама бирелә | | |
| 3 | Дератизацияләү эшләре: | | |
| 3.1 | Биналарда дератизацияләү | кв.м. | 1,33 |
| 3.2 | 100 кв.м.кадәрге биналарда дератизацияләү | хезмәт | 251,06 |
| 3.3 | 100 кв.м.кадәрге биналарда бөҗәкләргә мониторинг | хезмәт | 269,69 |
| 3.4 | 101 кв.м.артык биналарда бөҗәкләргә мониторинг | кв.м. | 0,95 |
| 3.5 | Территорияләрне дератизацияләү | кв.м. | 1,01 |
| 3.6 | Шәһәрдә дезинсекцияләү | кв.м. | 9,35 |
| 3.7 | Авыл җирлегендә дезинсекцияләү | кв.м. | 12,57 |
| 3.8 | Подвалларда борчалардан, кандалалардан һ.б. дезинсекцияләү | кв.м. | 18,91 |
| 3.9 | Шәһәрдә (аерым фатирларны) дезинсекцияләү | хезмәт | 4108,69 |
| 3.10 | Талпаннарга каршы эшкәртү | кв.м. | 1,52 |
| 3.11 | Шәһәрдә чебеннәр белән көрәшү | кв.м. | 4,66 |
| 3.12 | Авыл җирлегендә чебеннәр белән көрәшү | кв.м. | 7,68 |
| 3.13 | Шәһәрдә профилактик дезинфекцияләү | кв.м. | 8,78 |
| 3.14 | Авыл җирлегендә профилактик дезинфекцияләү | кв.м. | 14,01 |
| 3.15 | Мәеттән соң фатирда профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 3283,60 |
| 3.16 | 10 кг кадәр керне камерада дезинфекцияләү | хезмәт | 336,08 |
| 3.17 | Автотранспортны профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 343,44 |
| 3.18 | Канализациягә тоташмаган бәдрәфләрне профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 202,28 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева